БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ
ВСЕМИРНЫЙ КОНГРЕСС ТАТАР
WORLD CONGRESS OF THE TATARS

420060, Казань-60, Всемирный конгресс татар,
тел.: (843) 236 59 16, факс: (843) 264 63 37
www.tatar-congress.org

420060, Казан шәһәре,
Бөтендөнья татар конгрессы
тел.: (843) 236 59 16, факс: (843) 264 63 37
E-mail: tatar-congress@mail.ru

Исх. № 19-124 от «1» 02.2018

на №

**Татар иҗтимагый
оешма җитәкчеләренә**

Берничә ел дәвамында төрле өлкәләрдә уздырылып килә торган “Татар кызы” бәйгесенең даны Россия төбәкләре арасында гына кызыксындыру уяндырып калмыйча, 2016 елдан башлап халыкара дәрәҗәгә күтәрелеп, күчмә форматта үткәрелеп килә.

2018 елны халыкара “Татар кызы” бәйгесендә 30га якын Россия төбәге һәм 3 чит ил катнашты. Ярым финал этабында кызлар төрле сынаулар узды, татар халкының тарихы һәм гореф-гадәтләре өлкәсендә үз белемнәрен күрсәтте. Финал Казан шәһәренең М.Җәлил исемендәге Татар академия опера һәм балет театрында бер мең тамашачы каршында узды, һәр катнашучы үз төбәген һәм татар мәдәниятының бай, күпкырлы булуын ачып бирә алды.

Бәйге өч этаптан тора: Россия Федерациясе төбәкләрендә һәм чит илләрдә сайлап алу туры, ярым финал Казан шәһәрендә һәм агымдагы елның 27 сентябрендә Удмурт Республикасының Ижевск шәһәрендә узачак.

Хөрмәтле татар иҗтимагый оешма җитәкчеләре! Сезнең төбәктән 2019 елның 15 нче февраленә кадәр конкурсның уздыру датасын, урынын һәм җаваплы вәкил билгеләүегезне сорыйбыз. Әлеге мәгълүматны tatarkizi2019@gmail.com электрон адресына юлларга кирәк.

Беркетмә: нигезләмә 5 биттә.

**Олы ихтирам белән,**

**Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары,
Бөтендөнья татар конгрессы
Милли Шурасы рәисе** **В.Г.Шәйхразиев**